| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«СТАРОИШТИРЯКСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ИСКЕ ИШТИРӘК<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2021 елның 28 октябре № 4

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Иштирәк авыл җирлеге Ялтау авылында гражданнарның үзара салым акчасын кертү һәм файдалану буенча гражданнар җыены үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы «Иске Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск муниципаль районы Иске Иштирәк авыл җирлеге Ялтау авылында үзара салым акчасын кертү буенча гражданнар җыенын 2021 елның 20 ноябрендә 09 сәгать 00 минутта дип билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2022 елда үзара салым кертүгә Лениногорск муниципаль районы Иске Иштирәк авыл җирлеге Ялтау авылында территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган яшәүчедән, беренче һәм икенче төркем инвалидлар, түләүле нигездә укучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә акча кертү һәм җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме:

- җирлекнең су үткәрү мөлкәтен ремонтлау объектларының расланган исемлеге нигезендә бирелгән вәкаләтләр нигезендә суүткәргеч мөлкәтен карап тоту
- урамнарны яктыртуны оештыру;
- авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә юлларны карап тоту;
- авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә юлларны вак ташлау;
- җирлек территориясен төзекләндерү һәм яшелләндерү;

«ӘЙЕ» «ЮК».

3. Әлеге карарны Лениногорск районы, Иске Иштирәк авылы, Мәктәп урамы, 15; Бакирово авылы, Нагорная урамы, 38; Ялтау авылы, Тынычлык урамы, 27,,адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
“Иске Иштирәк авыл җирлеге"
муниципаль берәмлеге башлыгы А.А.Вәлиәхмәтов